КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 ноябрь г.Казань № 1062

Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру чараларын тормышка ашыру буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының финанс чыгымнары нормативларын раслау турында

«Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге V категорияле автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру чараларын тормышка ашыру буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетының финанс чыгымнары нормативларын расларга:

1 километрга 11,779 мең сум – юл хәрәкәтен оештыру проектларын эшләүгә;

1 километрга 8,947 мең сум – юл хәрәкәтен мониторинглауга;

1 участокка 1,740 мең сум – юл хәрәкәте белән автоматлаштырылган идарә итүгә.

2. Юл хәрәкәтен оештыру чараларын тормышка ашыру буенча эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү автомобиль юллары категорияләре буенча төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру проектларын әзерләү кыйммәтен дифференциацияләүне исәпкә ала торган коэффициентны кулланып гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

| Автомобиль юллары категорияләре | IА, IБ, IВ | II | III | IV | V |
|---|---|---|---|---|---|
| Коэффициенты | 2,91 | 2,50 | 2,08 | 1,66 | 1,00 |

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин